ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

09.06.2025 М ө с л и м № 276

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының «Кулланучылар кооперациясе оешмаларының Мөслим муниципаль районының район үзәгеннән – Мөслим авылыннан 11 километр ераклыкта урнашкан ерак авыл пунктларына беренче кирәк-ярак товарларын илтүгә бәйле чыгымнар өлешен каплауга Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2024 елның 17 октябрендәге 442 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Кадрлар үзгәрешләренә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының «Кулланучылар кооперациясе оешмаларының Мөслим муниципаль районының район үзәгеннән – Мөслим авылыннан 11 километр ераклыкта урнашкан ерак авыл пунктларына беренче кирәк-ярак товарларын илтүгә бәйле чыгымнар өлешен каплауга Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2024 елның 17 октябрендәге 442 номерлы карарына яңа редакциядә бәян итеп, әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә үзгәрешләр кертергә.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында халыкка җиткерергә http://pravo.tatarstan.ru.
3. Әлеге карар рәсми рәвештә халыкка игълан ителгәннән соң законлы көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И. Ф. Салихҗанов**

Татарстан Республикасы
Мөслим муниципаль районы
Башкарма комитетының 2025 елның
«09» июнендәге 276 номерлы карарына
1 нче кушымта

Субсидия алу хокукына дәгъва кылучы юридик затларны, индивидуаль эшкуарларны, физик затларны сайлап алуны гамәлгә ашыручы комиссия **составы**

| N т/б | Вазыйфа | Ф.И.О. |
|---|---|---|
| 1 | Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе- рәис | Салихҗанов И.Ф. |
| 2 | Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары - рәис урынбасары | Мөхсинов Р.В. |
| 4 | Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге башлыгы-әгъза | Каримова Л.М. |
| 5 | Мөслим муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы рәисе (килешү буенча) | Бубекова Н.А. |
| 6 | Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Контроль-хисап палатасы рәисе (килешү буенча) | Срүрова Л.Р. |
| 7 | Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге башлыгы (килешү буенча) | Гайсина Г.Р. |
| 8 | ТР Мөслим муниципаль районы Башлыгы ярдәмчесе | Бәдретдинов Н.А. |